



# Сак-Сок бәете

**БӘЕТ** – **татар халык авыз иҗатының лиро-эпик жанры.** Аның нигезендә кайгылы яисә көлкеле вакыйга ята. Әсәр шул вакыйга нәтиҗәсендә кеше күңелендә туган хис-кичерешләрне бәян итә.


Бәет – гарәп сүзе, ике юллы шигырь дигәнне аңлата. Бу жанр әсәрләре халык телендә ***бәет*** дип кенә түгел, ***мөнәҗәт*** дип тә, ***җыру*** дип тә, ***әрбагый*** дип тә йөртелә.

Бәетләр һәммәсе диярлек тарихи, аларның берсе дә хыялый-фантастик вакыйгаларга багышланмаган.

Бәет нигезендә - булган хәл-вакыйга ята.

## Бәетләрнең төркемнәре:

1. **Тарихи вакыйгалар һәм шәхесләргә багышланган бәетләр**
   (“Казан бәете” һәм "Сөембикә бәете“ - Явыз Иван чорында Казанның урыслар тарафыннан яулап алынуы сурәтләгәннәр)
2. **Тарихи шәхесләргә багышланган бәетләр** (“Акмулла бәете”, “Тукай бәете“)
3. **Хәрби-тарихи бәетләр**
   (халык телендә сугыш бәетләре дип тә йөртеләләр. “Рус-француз”, “Рус-төрек”, “Рус-япон”, “Герман сугышлары” турындагы кебек бәетләр)
4. **Авыр замана, ирексез хезмәт турында бәетләр**
   (ялчылар, бурлаклар, шахтада эшләүчеләрнең авыр хезмәтенә багышланган “Шахта бәетләре”, “Лашманчылар бәете”)
5. **Җир, ирек өчен көрәш темасын яктырткан бәетләр**
   (“Урта Тигәнәле”, “Чынлы”, “Ышна” бәетләре. Бу бәетләрдә патша хөкүмәтенең, җирле властьларның хезмәт ияләрен изү-җәберләүләре, халыкның үз хокукларын яклап көрәшүләре күрсәтелә)
6. **Сатирик бәетләр**
   (кешеләрнең саранлыгы, ялкаулыгы, эш рәте белмәүләре тәнкыйть ителә. Бу бәетләр җәмгыятьнең әхлак нормаларын саклый, тәрбияви функция белән иҗат ителә)
7. **Сак-Сок бәетләре**
   (“Сак-Сок” бәете вариацияләнеп, үзенең билгеле көе белән әйтелә. Хәзер дә аның калыбында яңа бәетләр чыгарыла)



1. Әниләре балаларын ни өчен орыша һәм каргый?
2. Әниләре каргаганнан соң малайлар нинди кыяфәткә керәләр?
3. Ике туган ни өчен кавыша алмыйлар?
4. Сез ничек уйлыйсыз: ни өчен әти-әнинең сүзен тыңларга кирәк?
5. Ә сезгә әти-әниләрегез нәрсәләр өйрәтәләр, нинди киңәшләр бирәләр?
6. Сез аларның сүзләрен һәрвакытта да тыңлыйсызмы соң?

- **Ата – ак тирәк, бала яфрак.** /Отец – белая ива, дитя – лист./
- **Ата һөнәре – балага мирас.** /Профессия отца – наследие детям./
- **Алтын-көмешнең искесе булмас, ата-ананың бәһасе булмас.** /Золото-серебро старым не будет, родителям цены не будет./
- **Аналы-аталы – алтын канатлы.** /С родителями – с золотыми крыльями./
- **Ата-анаңны тәрбия ит, үзең дә тәрбия күрерсең.** /Уважай родителей , и тебя будут уважать./
- **Ата – беләк, ана – йөрәк.** /Папа – рука, мама – сердце./
- **Әткәй – шикәр, әнкәй – бал.** /Отец – сахар, мать – мед./
- **Ата-ананы тыңлаган адәм булган, тыңламаган, әрәм булган.** /Послушался родителей – стал человеком, не послушался – пропал./
- **Ана өйрәтсә, балалар җитез булыр; ата өйрәтсә балалар акыллы булыр.** /Мать научит детей проворству, отец - уму./